Ядегәр авыл җирлеге Советы

КАРАР

29.11.2021 ел. № 35

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 19 пункты, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Уставы нигезендә Ядегәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында кушып бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карар, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәнең 5 бүлегендәге нигезләмәләрдән тыш, ул рәсми басылып чыккан көннән дә соңга калмыйча, әмма 2022 елның 1 гыйнварыннан иртәрәк түгел, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәнең 5 бүлегендәге Нигезләмәләр 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы: А.Н.Фәйзуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ЯДЫГЕРЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" ОГРН 1021607752836 Совет Ядыгерьского сельского поселения ИНН 1623001639

Ядегәр авыл җирлеге Советының 2021 елның «29» ноябреннән 35 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ядегәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибен билгели (алга таба – төзекләндерү өлкәсендә контроль).

1.2. Төзекләндерү өлкәсендә контроль предметы булып, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар (алга таба – контроль үткәрелә торган затлар) тарафыннан Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен (алга таба – Төзекләндерү кагыйдәләре), инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәү тора.

1.3. Төзекләндерү өлкәсендә контроль Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет, җирлек) тарафыннан башкарыла.

1.4. Башкарма комитетның төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары – *Ядегәр авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет секретаре (алга таба – контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар).* Күрсәтелгән вазыйфаи затларның вазыйфаи бурычларына аларның вазыйфаи инструкциясе нигезендә төзекләндерү өлкәсендә контрольлек итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру керә.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә, төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар хокуклы, бурычлы һәм җаваплылык тота.

1.5. Төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәрү, профилактик чаралар, контроль чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

1.6. Башкарма комитет түбәндәгеләрне үз эченә алган төзекләндерү Кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота:

1) якын-тирә территорияләрне карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр;

2)төзекләндерү элементларын һәм объектларын карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән түбәндәге таләпләр:

- халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, физик культура һәм спорт, социаль хезмәт күрсәтү объектларына иркенле үтеп керүенә комачауламый торган киртәләр урнаштыру буенча;

- торак булмаган биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның башка стеналарының, шулай ук төзекләндерүнең һәм җәмәгать урыннарының башка элементларының фасадларын карап тоту буенча;

- инженерлык корылмаларын эксплуатацияләү өчен кирәкле мәгълүматны үз эченә алган махсус билгеләрне, язуларны карап тоту буенча;

- Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында һәм төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән җир эшләрен башкару тәртибе нигезендә бирелә торган җир эшләрен башкаруга рөхсәтнамә нигезендә җир эшләрен башкару буенча;

- җир эшләрен башкару чорында биналарга һәм аларга керү юлларына иркенле үтеп керүне, шулай ук ишегалларына иркенле керү юлларын тәэмин итү, җәяүлеләрнең, шул исәптән инвалидларның һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең иминлеген һәм җәяүле юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча;

- транспорт чараларын газонда яки транспорт чараларын урнаштыру төзекләндерү кагыйдәләре белән чикләнгән башка яшелләндерелгән яки рекреацион территориядә урнаштыруга юл куймау, шулай ук эксплуатацияләү, хезмәт күрсәтү яки ремонтлау вакытында, йөк ташыганда яки төзелеш мәйданнарыннан чыкканда (тент яисә каплау булмау нәтиҗәсендә) транспорт чаралары тарафыннан гомуми файдалану территорияләренең пычрануына юл куймау буенча да;

3) кышкы чорда җирлек территориясен җыештыру, шул исәптән кардан, боз өстенә чыккан судан, биналарның, корылмаларның түбәләрен боз сөңгеләреннән чистарту буенча чаралар үткәрүне контрольдә тоту буенча мәҗбүри таләпләр;

4) җәйге чорда җирлек территориясен җыештыру буенча, шул исәптән карантинга куелган, агулы һәм чүп үләннәрен ачыклау, аларга каршы көрәш, аларны локальләштерү, алар күпләп үскән урыннарны бетерү буенча мәҗбүри таләпләрне дә кертеп, мәҗбүри таләпләр;

5) махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычсызлыгының өстәмә мәҗбүри таләпләре;

6) гомуми файдаланудагы территорияләрдә җир асты коммуникацияләрен салу, үзгәртеп кору, ремонтлау һәм карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр;

7) яшел утыртмаларны утырту, саклау һәм карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән кисү билетлары (порубочный билет) һәм (яки) рөхсәт нигезендә агач һәм куакларны алу (снос), күчереп утырту буенча мәҗбүри таләпләр, әгәр мондый документлар (күчереп утыртуга рөхсәт, кисү билеты) төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән очракларда бирелергә тиеш булса);

8) каты коммуналь калдыкларны туплау буенча мәҗбүри таләпләр;

9) хайваннарны йөртү буенча мәҗбүри таләпләр һәм гомуми файдаланудагы территорияләрдә һәм төзекләндерү кагыйдәләре белән каралган башка территорияләрдә авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын көтүгә юл куймау турында мәҗбүри таләпләр.

Башкарма комитет контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үз компетенцияләре чикләрендә бирелгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрнең үтәлешен контрольдә тота.

1.7. Әлеге Нигезләмәдә төзекләндерү элементлары дигәндә декоратив, техник, планировка, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, төрле җиһазлар һәм бизәлеш элементлары, шул исәптән биналарның, корылмаларның, төзелмәләрнең фасадларының, кече архитектура формалары, капиталь булмаган стационар булмаган корылмалар һәм төзелмәләр, территорияне төзекләндерүнең состав өлешләре буларак кулланыла торган мәгълүмат щитлары һәм күрсәткечләр аңлашыла.

Әлеге Нигезләмәдә төзекләндерү объектлары дигәндә төзекләндерү эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган төрле функциональ билгеләнештәге территорияләр аңлашыла, шул исәптән:

1) планлаштыру структурасы элементлары (зоналар (массивлар), районнар (шул исәптән торак районнар, микрорайоннар, кварталлар, сәнәгать районнары), гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек коммерцияле булмаган берләшмәләрен урнаштыру территорияләре);

2) урам-юл челтәре элементлары (аллеялар, бульварлар, магистральләр, тыкрыклар, мәйданнар, проездлар, проспектлар, тыкрыклар, разъездлар, авышлыклар, трактлар, тупиклар, урамнар, шосселар);

3) ишегалды территорияләре;

4) балалар һәм спорт мәйданчыклары;

5) хайваннарны йөртү өчен мәйданчыклар;

6) транспорт туктап тору урыны (парковкалар) (парковка урыннары);

7) парклар, скверлар, башка яшел зоналар;

8) техник һәм санитар-яклау зоналары;

Киртәләү җайланмалары дигәндә капкалар, калиткалар, шлагбаумнар, шул исәптән автоматик һәм декоратив киртәләр (коймалар) аңлана.

1.8. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда бәяләү һәм куркынычлар (риск) белән идарә итү системасы кулланылмый.

## 2. Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыяюгалту) китерү куркынычларын профилактикалау

2.1. Башкарма комитет төзекләндерү өлкәсендә шул исәптән профилактик чаралар үткәрү юлы белән дә контрольлек итә.

2.2. Профилактик чаралар контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намус белән үтәүне стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яки) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүгә китерә торган шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү һәм мәҗбүри таләпләрне, аларны үтәү ысулларын контроль үткәрелә торган затларга җиткерү максатларында Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.3. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне тормышка ашырганда зыян (югалту) китерү куркынычын киметүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү контроль чаралар үткәрүгә карата өстенлекле булып тора.

2.4. Профилактик чаралар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычларын профилактикалау программасы нигезендә гамәлгә ашырыла, шулай ук зыян китерү куркынычын профилактикалау программасында каралмаган профилактик чаралар үткәрелергә мөмкин.

Профилактик чаралар үткәргәндә контроль объектларының закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүгә турыдан-туры куркыныч тудыруы яки мондый зыян (югалту) китерелүе ачыкланган очракта, төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи зат бу хакта кичекмәстән җирлек башлыгына, контроль чаралар үткәрү турында карар кабул итү өчен, үткәрелгән профилактик визит турында хисап рәвешендә мәгълүмат җибәрә.

2.5. Башкарма комитет тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәргәндәтүбәндәге профилактик чаралар уздырылырга мөмкин:

1) мәгълүмат бирү;

2) консультация бирү.

2.6. Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча тиешле мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (алга таба – районның рәсми сайты) контрольлек эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә (махсус бүлеккә керү районның рәсми сайтының төп (төп) битеннән булырга тиеш), массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән, контроль үткәрелә торган затларның дәүләт мәгълүмат системаларында шәхси кабинетлары аша (алар булганда) һәм башка формаларда Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

Башкарма комитет районның рәсми сайтындагы контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлешендә каралган мәгълүматларны урнаштырырга һәм актуаль хәлдә тотарга бурычлы.

Башкарма комитет шулай ук җирлек халкына җыелышлада һәм гражданнар конференцияләрендә контроль объектларына куелган мәҗбүри таләпләр турында хәбәр итәргә хокуклы.

2.7. Контроль үткәрелә торган затларга консультация бирү телефон аша, видео-конференц-элемтә аша, шәхсән кабул итү яки профилактик чаралар, контроль чаралар уткәрү барышында контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм 15 минуттан артмаска тиеш.

Гражданнарны шәхсән кабул итү җирлек башлыгы һәм (яки) контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан башкарыла. Кабул итү урыны, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат районның рәсми сайтында контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә урнаштырыла.

Консультация телдән яки язма формада түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелә:

1) төзекләндерү өлкәсендә контроль оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән контроль чараларны гамәлгә ашыру тәртибе;

3) контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тәртибе;

4) үтәлешләрен бәяләү Башкарма комитет тарафыннан контроль чаралар кысаларында гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар (аларның аерым нигезләмәләре) турында мәгълүмат алу.

Контроль үткәрелә торган затларга телдән консультация бирү шулай ук җыелышларда һәм гражданнар конференцияләрендә дә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2.8. Язма рәвештә консультация бирү контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан түбәндәге очракларда башкарыла:

1) контроль үткәрелә торган зат тарафыннан консультация мәсьәләләре буенча язмача җавап бирү турында язмача сорату бирелгән;

2) консультацияләр вакытында куелган сорауларга телдән җавап бирү мөмкин түгел;

3) куелган сорауларга җавап бирү өстәмә мәгълүмат соратып алуны таләп итә.

Консультация биргәндә контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи заты Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга тиеш.

Консультация бирү барышында конкрет контроль чарасын, контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларын һәм (яки) гамәлләрен, контроль чарада катнашучыларның башка гамәлләрен бәяләгән мәгълүмат, шулай ук контроль чара кысаларында үткәрелгән экспертиза, сынаулар нәтиҗәләрен үз эченә алган мәгълүмат бирелә алмый.

Консультация барышында контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затка билгеле булган мәгълүмат Башкарма комитет тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча контроль үткәрелә торган затны бәяләү максатларында кулланыла алмый.

Контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан консультацияләрне исәпкә алу журналы алып барыла.

Башкарма комитетка контроль үткәрелә торган затлардан һәм аларның вәкилләреннән биш һәм аннан күбрәк мөрәҗәгать кергән очракта, консультация бирү районның рәсми сайтында контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә авыл җирлеге башлыгы яки контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи зат кул куйган язма аңлатма урнаштыру юлы белән башкарыла.

## 3. Контроль чаралар һәм контроль гамәлләр башкару

3.1. Башкарма комитет тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда күрсәтелгән чаралар кысаларында түбәндәге контроль чаралар һәм контроль гамәлләр үткәрелергә мөмкин:

а) инспекция визиты (карау, сораштыру, мәҗбүри таләпләр нигезендә контроль үткәрелә торган зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашкан (эшчәнлек алып бара торган) урында булырга тиеш булган документларны таләп итү, язма аңлатмалар алу, инструменталь тикшереп чыгу (обследование) юлы белән;

2) рейд тикшерүе (карау, сораштыру, язмача аңлатмалар алу, документларны соратып алу, инструменталь тикшерү, сынаулар, экспертиза аша);

3) документар тикшерү (язмача аңлатмалар алу, документлар таләп итү, экспертизалар юлы белән);

4) күчмә (урынга барып) тикшерү (карау, сораштыру, язмача аңлатмалар алу, документларны соратып алу, инструменталь тикшерү, сынаулар, экспертиза аша);

5) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (төзекләндерү өлкәсендә контроль объектлары турында мәгълүматларны, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында керә торган, мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында контроль үткәрелә торган

затлар тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларындагы мәгълүматларны, «Интернет» челтәреннән алынган мәгълүматларны, һәркем өчен ачык булган мәгълүматларны, шулай ук фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган хокук бозуларны теркәүнең автоматик режимында эшләүче техник чараларын кулланып алынган мәгълүматларны җыю, анализлаудан гыйбарәт;

е) күчмә тикшереп чыгу (карау, инструменталь тикшереп чыгу (видеоязма кулланып), сынау, экспертиза юлы белән).

3.2. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү һәм күчмә тикшерү – Башкарма комитет тарафыннан контроль үткәрелә торган затлар белән үзара хезмәттәшлек итмичә уздырыла.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән контроль чаралар планнан тыш чаралар формасында үткәрелә.

Планнан тыш контроль чаралар бары тик прокуратура органнары белән килештерелгәннән соң гына үткәрелергә мөмкин.

3.4. Контроль үткәрелә торган затлар белән үзара хезмәттәшлектә үткәрелә торган контроль чаралар уздыру өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гражданнар һәм оешмалардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мөрәҗәгатьләр (гаризалар) кергәндә Башкарма комитетта зыян (югалту) китерү яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы турында белешмәләрнең булуы, шулай ук контроль чаралар үткәрү нәтиҗәсендә, үзара хезмәттәшлектән башка контроль чараларны, шул исәптән контрольдә тотылучы бүтән затларга карата үткәрелә торган чараларны да кертеп, мондый мәгълүматлар алу;

2) Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контроль үткәрелә торган затларга карата контроль чаралар үткәрү турында күрсәтмәсе;

3) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

4) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очракларын бетерү турында күрсәтмәнеүтәү срогы чыгу – контроль үткәрелә торган зат тарафыннан аңа бирелгән күрсәтмә белән бирелгән каралган документлар һәм белешмәләр тапшырылмаган яки тапшырылган документлар һәм белешмәләр нигезендә ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турында күрсәтмәнең үтәлеше турында нәтиҗә ясау мөмкин булмаган очракта.

3.5. Контроль үткәрелә торган зат белән үзара хезмәттәшлектә үткәрелә торган контроль чаралар Башкарма комитетның контроль чарасы үткәрү турындагы күрсәтмәсе нигезендә уздырыла.

3.6. Зыян (югалту) китерү яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы турында белешмәләр нигезендә контроль чара үткәрү турында Башкарма комитет боерыгы кабул ителгән очракта, контроль чара үткәрү турында мондый боерык төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затның дәлилле гаризасы (представление) нигезендә кабул ителә.

3.7. Контроль үткәрелә торган затлар белән үзара хезмәттәшлектән башка үткәрелә торган контроль чаралар, җирлек башлыгы биреме, Башкарма комитетның эш планындагы биремнәр нигезендә, шул исәптән «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан уздырыла.

3.8. Гражданнарга, юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата контроль чаралар «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә.

3.9. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне оештырганда һәм гамәлгә ашырганда, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, шул исәптән электрон формада Башкарма комитет түләүсез нигездә бүтән органнардан яки күрсәтелгән органнарга караган

оешмалардан алар карамагында булган документларны һәм (яки) белешмәләрне ала. Күрсәтелгән документлар һәм (яки) белешмәләр исемлеге, аларны тапшыру тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы белән расланган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан әлеге документлар һәм (яисә) мәгълүмат алар карамагында булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалардан тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратыла һәм алына торган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар исемлеге белән, шулай ук контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләрен, муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашырганда әлеге документлар һәм (яки) белешмәләр алар карамагында булган бүтән органнардан яисә күрсәтелгән органнарга караган оешмалардан дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләрен, муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашырганда алына торган «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2001 елның 6 мартындагы 338 номерлы карары белән расланган ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) белешмәләр бирү Кагыйдәләре белән билгеләнгән.

3.10. Контроль үткәрелә торган затлар булган шәхси эшмәкәр, граждан Башкарма комитетка контроль чарасы үткәргәндә була алмаулары турында мәгълүмат бирергә хокуклы булган, шуның нәтиҗәсендә тикшерү чарасын үткәрү башкарма комитет тарафыннан шәхси эшмәкәрнең, гражданның администрациягә әлеге мөрәҗәгатьне юллавына сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка (әмма 20 көннән дә артык түгел) күчерелү очрагына бер үк вакытта түбәндәге шартларны үтәү дә керә:

1) контроль үткәрелә торган затның яисә аның вәкиленең булмавы, контроль үткәрелә торган затка тиешле рәвештә контроль чара үткәрү турында хәбәр ителгән булса, төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затка контроль чарасы үткәргәндә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләргә комачауламый;

2) законда саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүнең яисә фактта зыян китерүнең турыдан-туры янавы билгеләре булмау;

3) контроль чара үткәргәндә контроль үткәрелә торган затның булмавына җитди сәбәпләр (контроль үткәрелә торган затның авыруы, аның командировкада булуы һ.б.) бар.

3.11. Күчмә тикшерү үткәрү вакыты 10 эш көненнән дә артырга тиеш түгел.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата күчмә тикшерү уздыру барышында хезмәттәшлекнең гомуми вакыты кече предприятие өчен 50 сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен 15 сәгатьтән арта алмый.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Оешмага карата күчмә тикшерүне үткәрү вакыты һәр филиал, вәкиллек, оешманың аерымланган структур бүлекчәсе яисә житештерү объекты буенча аерым билгеләнә.

3.12. Контроль чараларны уздыруның барлык очракларында да контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар һәм контроль үткәрүгә җәлеп ителгән затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү (бозу) дәлилләрен беркетү өчен контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма, геодезия һәм картометрик үлчәүләр кулланылырга мөмкин. Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязмалар, геодезик һәм картометрик үлчәүләр һәм бу максатлар өчен кулланылган техник чаралар турындагы мәгълүмат контроль чара нәтиҗәләре буенча төзелә торган актта һәм контроль чара кысаларында үткәрелә торган контроль гамәл нәтиҗәләре буенча төзелә торган беркетмәдә чагыла.

3.13. Контроль чарасы нәтиҗәләренә контроль үткәрелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен бәяләү, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү һәм (яки) аларны бозуларны туктату өчен шартлар тудыру, бозылган нигезләмәне торгызу, вәкаләтле органга яисә вазыйфаи затларга җаваплылыкка тарту мәсьәләсен карау өчен мәгълүмат җибәрү һәм (яки) Башкарма комитет тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм

муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешендә каралган чараларны куллану кирә.

3.14. Контроль үткәрелә торган зат белән үзара бәйләнешне күздә тота торган контроль чара тәмамланганнан соң, контроль чара акты төзелә. Мондый чара үткәрү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланса, актта нәкъ менә нинди мәҗбүри таләп бозылуы, нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге тарафыннан билгеләнүе күрсәтелә. Ачыкланган бозуларны контроль чара тәмамланганчы бетергән очракта, актта аны бетерү факты күрсәтелә. Мәҗбүри таләпләрне бозуга дәлил булган документлар, башка материаллар актка теркәлергә тиеш. Контроль чараларын үткәргәндә тутырылган тикшерү кәгазьләре актка теркәлә.

Актны рәсмиләштерү, әгәр актны рәсмиләштерүнең башка тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәгән булса, мондый чараны үткәрү көнендә контроль чара үткәрү урынында башкарыла.

Прокуратура органнары тарафыннан килештерелгән контроль чара акты прокуратура органнарына Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестры ярдәмендә турыдан-туры аны рәсмиләштергәннән соң җибәрелә.

3.15. Контроль чаралар турында мәгълүмат Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрында урнаштырыла.

3.16. Контроль үткәрелә торган затларга контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләре һәм кабул итә торган карарлары турында хәбәр итү Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында әлеге гамәлләр һәм карарлар турында белешмәләр урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм дәүләт һәм муниципаль функцияләрне электрон формада башкару өчен файдаланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктура аша, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләр)» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша (алга таба – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы) һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталы аша да контроль үткәрелә торган затларга җиткерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Эшмәкәрлек эшчәнлеген башкармаучы, контроль үткәрелә торган зат булып торучы гражданга контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләре һәм кабул итә торган карарлары турында, ул документларны кәгазь чыганакта алырга кирәклеге турында Башкарма комитет адресына хәбәрнамә җибәргән яисә Башкарма комитетта контроль үткәрелә торган затның электрон почта адресы турында мәгълүмат һәм аңа документларны электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша җибәрү мөмкинлеге булмаган (әгәр затның Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында хисап язмасы булмаса яки Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәү процедурасын узуны төгәлләмәсә) очракта, документларны кәгазьдә тапшыру юлы белән хәбәр ителә. Күрсәтелгән граждан Башкарма комитетка документларны кәгазь чыганакта җибәрергә хокуклы.

2023 елның 31 декабренә кадәр контроль үткәрелә торган затка контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар башкара торган гамәлләр һәм кабул ителә торган карарлар турында хәбәр итү, Башкарма комитет тарафыннан контроль үткәрелә торган затка документлар һәм белешмәләр җибәрү, контроль үткәрелә торган затка электрон формада яки контроль үткәрелә торган зат соратуы буенча хәбәр итү мөмкинлеге булмаган очракта, почта элемтәсен кулланып, шул исәптән кәгазьдә дә гамәлгә ашырылырга мөмкин

3.17. Актта бәян ителгән фактлар һәм нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, контроль үткәрелә торган зат «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39-40 статьяларында һәм әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә каралган тәртиптә шикаять җибәрергә хокуклы.

3.18. Контроль чара үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланмаган очракта, бу хакта белешмәләр Контроль (күзәтчелек) чараларның Бердәм реестрына кертелә. контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи зат мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча киңәшләр

бирергә, закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычын профилактикалауга юнәлдерелгән башка чаралар үткәрергә хокуклы.

3.19. Контроль чара үткәргәндә контроль үткәрелә торган зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә Башкарма комитет (контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи зат) түбәндәгеләне башкарырга бурычлы:

1) контроль чарасы актын рәсмиләштергәннән соң, контроль үткәрелә торган затка, аларны бетерүнең тиешле срокларын күрсәтеп, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында һәм (яисә) законда саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүне булдырмау чаралары үткәрү турында күрсәтмә бирергә;

2) контроль чара барышында төзекләндерү өлкәсендә контроль объектына ия булган һәм (яки) аннан файдаланучы граждан, оешманың эшчәнлеге закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүнең турыдан-туры куркынычын тудыруы яисә мондый зыян (югалту) китерелгәнлеге ачыкланган очракта, саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерүне булдырмау яисә аны китерүне туктату буенча һәм закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычы янау булу һәм аны булдырмау ысуллары турында теләсә нинди үтемле ысул белән гражданнарга, оешмаларга мәгълүмат җиткерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кичекмәстән кабул итәргә;

3) контроль чара барышында җинаять яки административ хокук бозу билгеләрен ачыклаганда, үз компетенциясе нигезендә яисә гаепле затларны законда билгеләнгән җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә тиешле вәкаләтләре булганда,тиешле мәгълүматны дәүләт органына җибәрергә;

4) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә ихтимал булган зыян (югалту) китерүне булдырмау буенча чаралар күрергә, күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән очракта, аның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә, әгәр мондый чара законнарда каралган булса, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән хәтта судка мөрәҗәгать итү дә булырга мөмкин;

5) мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча рекомендацияләр бирү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (югалту) китерү куркынычын профилактикалауга юнәлтелгән башка чаралар үткәрү турында мәсьәләне карарга.

3.20. Контроль үткәрүче вазыйфаи затлар, төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, оешмалар һәм гражданнар белән билгеләнгән тәртиптә хезмәттәшлек итәләр.

Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру кысаларындагы контроль чара барышында Россия Федерациясе законнары белән административ һәм башка җаваплылык каралган законнар таләпләрен бозу ачыкланган очракта, контроль чара актында ачыкланган бозу билгеләре турында мәгълүмат күрсәтелә. Контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар әлеге актның күчермәсен тиешле җаваплылыкка тартуга вәкаләтле хакимият органына юллыйлар.

## 4. Башкарма комитет карарларына, төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү

4.1. Башкарма комитет карарларына, контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

4.2. Башкарма комитет карарларына, контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләре (гамәл кылмаулары) судка кадәр шикаять бирү тәртибе кулланылмый.

**5. Төзекләндерү өлкәсендә контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре**

5.1. Төзекләндерү өлкәсендә контрольнең нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Төзекләндерү өлкәсендә контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре, контроль өчен индикатив күрсәткечләр җирлек Советы тарафыннан раслана.

Җирлек башлыгы: А.Н.Фәйзуллин